ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 27 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $2^1$ өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), «2020 – 2026 елларда» сүзләрен «2020 елдан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2024, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) 2 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата, әлеге статьяның $3^1$ өлешендә күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш, салым ставкасы 2 процент күләмендә билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган һәм һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган күчемсез мөлкәт объектларына карата, халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләреннән (комплексларыннан) һәм алардагы урыннардан тыш, салым ставкасы 2025 елда – 1,2 процент күләмендә, 2026 елдан 2,5 процент күләмендә билгеләнә.»;»;

2) 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3^2$. Салым әлеге Законның $1^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларына, халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләреннән (комплексларыннан) һәм алардагы урыннардан тыш, һәм әлеге Законның 2 статьясындагы $3^1$ өлешендә күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларына карата исәпләнгән салым суммасының 60 проценты күләмендә түләнә.»;».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 03 октябрь
№ 72-ТРЗ